# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составынакерүче Керәшен Пакшины авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 7

«17» ноябрь, 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Кызыл Тауторак пунктында 2021 елның «17» ноябрендә узганү зарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Керәшен Пакшины авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Керәшен Пакшины авылы юлларын ком һәм вак таш салып төзекләндерү;
-Керәшен Пакшины авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
-Керәшен Пакшины авылында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру)

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 33 кешекертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 25 кеше, 75,7% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүленде:

«РИЗА» позициясеөчен 25 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ»позициясеөчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәянителгәннәрнигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Керәшен Пакшины узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныргa.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Керәшен Пакшины авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныргa: Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Керәшен Пакшины авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Керәшен Пакшины авылы юлларын ком һәм вак таш салып төзекләндерү;
-Керәшен Пакшины авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;
-Керәшен Пакшины авылында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру)

3. Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларыРегистрына кертү өченҗибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина